КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 апрель г.Казань № 531

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 6 июнь, 525 нче карары белән расланган 2022 – 2023 елларда электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2023 елларда электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 6 июнь, 525 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 декабрь, 1402 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2022 – 2023 елларда электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә

технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Тәкъдимнәрне (заявкаларны) сайлап алу түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла:

вәкаләтле орган сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән сайлап алуны үткәрү срогы эчендә тәкъдимнәрне (заявкаларны) кабул итүне гамәлгә ашыра һәм аларны, керү датасын һәм вакытын күрсәтеп, кергән көнне тәкъдимнәрне (заявкаларны) теркәү журналында терки;

вәкаләтле орган тәкъдимне (заявканы) теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көн эчендә вәкаләтле органга керү чираты тәртибендә әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында һәм 2.3.1 пунктчасында билгеләнгән сайлап алу таләпләренә һәм критерийларына туры килү-килмәвен тикшерә, шулай ук тәкъдим (заявка) составында тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерүне гамәлгә ашыра;

вәкаләтле орган, түбәндәге мәгълүматны күрсәтеп, кергән тәкъдимнәр (заявкалар) реестрын алып бара: сайлап алуда катнашучының исеме, заряд алу инфраструктурасы объектының адресы, файдалануга тапшырылган заряд җыю инфраструктурасы объектының саны һәм куәте;

вәкаләтле орган сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән тәкъдимнәрне (заявкаларны) кабул итү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көн эчендә сайлап алу нәтиҗәләре турында (сайлап алуны үткәрү йә тәкъдимне (заявканы) кире кагу турында) реестр төзи һәм сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү турында карар һәм субсидия бирү турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле орган сайлап алуда катнашучыга кабул ителгән карар турында Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара

системасы аша, электрон почта яки тәкъдимдә (заявкада) күрсәтелгән элемтәгә керү өчен башка реквизитлар ярдәмендә хәбәр итә;

сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган өч календарь көннән дә соңга калмыйча, вәкаләтле орган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында, шулай ук вәкаләтле орган сайтында түбәндәге белешмәне үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

тәкъдимнәрне (заявкаларны) карау датасы, вакыты һәм урыны;

тәкъдимнәре (заявкалары) каралган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

субсидия бирү турында килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.»;

3.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Субсидия бирү субсидия бирү турында килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Субсидия бирү турында килешү вәкаләтле органга субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган тугыз көн эчендә төзелә. Кирәк булганда субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү төзү кирәклеге турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә субсидия бирү турында килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән субсидия бирү турында килешүгә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзелә.»;

Тәртипнең 2 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

2022 – 2023 елларда электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 27 апрель, 531 нче
карары редакциясендә)

Форма

# Гарантия хаты

______________________________________________________________________

(юридик затның исеме, индивидуаль эшмәкәрнең Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

йөзендә _________________________________________________________________,

(вәкаләтле затның вазыйфасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

__________________________________________________________ нигезендә эш итүче,

(устав, Шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәве номеры (ОГРИП) таныклыгы, ышанычнамә реквизитлары)

моның белән тәкъдим (заявка) бирү көненә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага карата түбәндәгеләрне раслый һәм гарантия бирә:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау (сайлап алу үткәрелгән очракта, 2022 елда түбәндәге формулировка кулланылырга мөмкин: салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча 300 мең сумнан артмаган, түләнмәгән бурычы булмау);

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) федераль бюджетка һәм Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау (2023 елда сайлап алуны үткәргән очракта);

сайлап алуда катнашучы юридик зат үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшмәкәрләр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмаска тиеш;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат, сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлар тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмау (2022 елда сайлап алу үткәрелгән очракта);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2023 елларда электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 6 июнь, 525 нче карары белән расланган 2022 – 2023 елларда электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю

инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый.

______________________________________________________________________
(юридик затның исеме, индивидуаль эшмәкәрнең Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2023 елларда электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 6 июнь, 525 нче карары белән расланган 2022 – 2023 елларда электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 2.3.2 пункты нигезендә җайланма урнаштыру чыгымнары Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия акчасы исәбеннән каплауга заявкага бирелә торган заряд җыю инфраструктурасының билгеләнгән объектларына карата сервис хезмәте күрсәтүнең һәм техник файдалану мөмкинлегенең түбәндәге таләпләре тәэмин ителәчәк дип гарантия бирә:

заряд алу инфраструктурасы объекты урнаштырылган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органы вәкаләтле вәкиле тарафыннан шул исәптән кул куелган, заряд алу инфраструктурасы объектын файдалануга тапшыруны раслый торган ак бирелгән көннән кимендә биш ел эчендә заряд алу инфраструктурасы объекты эшләү;

заряд алу инфраструктурасы объектында билгеләнгән хезмәт күрсәтү срогы эчендә тәүлек буе файдалану режимы булу. Торак пунктта заряд алу инфраструктурасы объектыннан файдалану мөмкинлеге аннан файдаланучылар өчен аена кимендә 80 процент тәшкил итә. Заряд алу инфраструктурасы объекты төзек булмаган очракта, эшли башлау сәләтен торгызу вакыты – иң күбе 48 сәгать. Федераль һәм төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлында заряд алу инфраструктурасы объектыннан файдалану мөмкинлеге аннан файдаланучылар өчен аена кимендә 95 процент тәшкил итә. Заряд алу инфраструктурасы объекты төзек булмаган очракта, эшли башлау сәләтен торгызу вакыты – иң күбе 12 сәгать;

электр транспорты хуҗаларының һәм (яки) аларны йөртүчеләрнең заряд алу инфраструктурасыннан файдалану уңайлыгын тәэмин итү өчен заряд алу инфраструктурасы объектының техник параметрлары һәм эш режимы турында аналитик мәгълүматлар тапшыру;

заряд алу инфраструктурасы объектының техник параметрлары һәм эш режимы турында түбәндәге аналитик мәгълүматларны вәкаләтле органга тапшыру:

бер заряд алу инфраструктурасы объектының электр энергиясен ай саен һәм квартал саен куллану;

ай, квартал эчендә заряд алу инфраструктурасы объектын ничә тапкыр куллану саны;

заряд алу инфраструктурасы объектларыннан файдаланучылар саны;

заряд алу инфраструктурасы объекты җиһазландырылган коннекторлардан бик күп файдалану турында мәгълүмат.

Сайлап алуда катнашучы _____________ _______ / _____________________________

(вазыйфасы) (имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У.
(булганда)

20__ ел, «__» ________

________________________